| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ НОРМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«2» август 2019 ел № 142

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2010 елның 15 декабрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы регламентын раслау турында " гы 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма авыл җирлеге Уставы нигезендә, Норма авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2010 елның 15 декабрендәге карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 4 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә: «**Җирлекнең даими комиссияләре алдан җирлек Советы утырышларында карау өчен сораулар әзерли һәм карый**»;

1.2 регламентның 5 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә: «**Җирлек советы, аның даими комиссияләре, җирлек Советы депутатлары, җирлек башлыгы - җирлек Советы Рәисе (алга таба – җирлек башлыгы) һәм аның урынбасары эшчәнлеген хокукый тәэмин итү җирлек Советы тарафыннан башкарыла, шулай ук җирлек Советы, аның даими комиссияләре, җирлек Советы депутатлары, җирлек башлыгы һәм аның урынбасары эшчәнлеген оештыру, документаль, мәгълүмати, матди – техник яктан тәэмин итә**»;

1.3 22 статьяның 1 пунктында «**айга бер тапкыр**» сүзен «**өч айга бер тапкыр**» сүзләре белән алмаштырырга:

1.4 22 статьяның 2 пунктында «**җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән икесе**» сүзен «**Сайланган депутатларның билгеләнгән санынннан 50 процент**» сүзләре белән алмаштырырга;

1.5 22 статьяның 3 пунктында «**депутатлар санынннан өчтән икесе**» сүзен «**Сайланган депутатларның билгеләнгән санынннан 50 процент**» сүзләре белән алмаштырырга;

1.6 25 статьяның 1 нче пуктындагы «**анын юклыгы очрагында**» сүзеннән сон «**утырышны алып бара**» сүзләрен стэргэ;

1.7 29 статьяның 1 пунктында «**сәгать 9дан 12 сәгатькә кадәр**» сүзләрен «**эш вакытында**» сүзләре белән алмаштырырга;

1.8 37 статьяның 7 пунктына «**һәм дөрес түгел дип таныла**» сүзләрен өстәргә;

1.9 63 статьяның 2 пунктында «**район Советы**» сүзләрен «**Җирлек Советы**» сүзләре белән алмаштырырга;

1.10 66 статьяның 2 пунктын «**Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы җирлек Советы, ә икенче яртысы – Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә»** сүзләре белән тулыландырырга;

1.11 Регламентның 75 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә «**Җирлек Советының һәр карарында, кагыйдә буларак, җирлекнең аның үтәлешен контрольдә тоту йөкләнгән вазыйфаи заты күрсәтелә**»;

1.12 76 статьяның 1 пунктында «**һәм авыл җирлеге башкарма комитеты эшчәнлеге**» сүзен төшереп калдырырга;

1.13 76 статьяның 2 пунктында «**яки аның урынбасары**» сүзен төшереп калдырырга;

1.14 76 статьясына 4 пункт өстәргә: **«Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе елга бер тапкыр җирлек советына үз эшчәнлеге турында хисап тапшыра».**

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Норма авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Норма авыл җирлеге башлыгы Шарипҗанов Р.Н.